**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422630 РТ, Лаишевский район,село
Нармонка,ул.Молодежная, д.12
тел: 8(84378)-4-62-24
факс:8-(84378)-4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422630,РТ, Нармонка авылы,
Яшьлэр урамы, 12 А нчы йорт,
тел: 8(84378)-4-62-24
факс:8-(84378)-4-62-24

---

**2023 елның 28 марты** **180 номер**

# КАРАР

**Җирле салымнары суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, Әгәр дә варислар закон буенча да, васыять буенча да юк икән, яки варисларның берсенең дә мираска хакы юк яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки барлык варислар да мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә баш тартуын башка варис файдасына күрсәтмәсә.;

2) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узу.

2. «Җирле салымнар буенча салымның вакытында түләнми калган өлешен, пеняларны һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 155 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–

адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

Башлык - Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Нармонка
авыл җирлеге - Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы **О.С. Мартынова**